УКУ ЯЛЫКТЫРГАН

Мәгариф өлкәсе өстенлекле юнәлешләрен билгеләде

> 2

ЭДУАРД ВАФИН:

«Яңа төр пособие гамәлгә кергәч, өч яшькә кадәрге балаларга пособие алучылар артачак»

> 3

БИШБАЛТА ГЕРОЕ

Ветеран Гарәфетдин Хисаметдинов үз хисабына һәйкәл салдырган

> 4

БӘЙРӘМ КӘЕФЕ

Йортларыгызда чыршылар бизәдегезме әле?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 189 (28962) | Чәршәмбе | 21 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

МОГҖИЗА КӨТКӘНДӘ

Өйдә генә утырмаска! Министрлар халыкка Яңа ел яллары алдыннан шундый киңәш бирде. Моның өчен шартларын да тудыралар, кәефкә һәм кесәгә карап сайлау мөмкинлеге дә бирәләр. Яңа ел каникулы чорында Татарстанның шәһәр һәм районнары ничек бәйрәм итәчәк?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ял итеп укыйлар

Сер түгел, Яңа елны зарыгып көтүчеләр – балалар. Алар өчен ял да сәгать уклары кушылганнан иртәрәк башлана бит. Каникул 28 декабрьдән 8 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк.

– Каникулны без игълан иткәч, нәрсәләр оештырылачагын да без әйтергә тиеш, – дип, алда көтелгән чаралар турында Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин сөйләде.

Иң элек министр куркынычсызлык мәсьәләсенә тукталды. Яңа ел ялларында моңа аерым игътибар бирү сорала. Мәктәп җыелышларында ата-аналарга җаваплылык, балалар сәламәтлеге һәм куркынычсызлыгы турында искә төшерәләр.

Чараларга килгәндә, алары да төрле юнәлештә оештырылачак. Балалар, ял итү белән беррәттән, белемнәрен, физик мөмкинлекләрен, сәләтләрен сынарга да өлгерәчәк. Лагерьларда профильле сменалар, белем олимпиадаларының йомгаклау этаплары, бәйгеләр көтелә. Кыскасы, балалар тик ятмаячак.

– Кышкы каникул чорында мәктәп балалары өчен 45 районда 2500дән артык бәйрәм чаралары оештыру күздә тотыла, – диде министр.

Мәктәп яны лагерьлары исә 28 декабрьдән эшли башлап, 10 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк. Республиканың 10 районында ачылачак 93 мәктәп яны лагере 3148 баланы колачлаячак. Илсур Һадиуллин, балалар күңелле итеп ял да итәчәк, белемнәрен дә арттырачак, дип ышандырды. Ата-аналарның лагерьларга взносы 196 сум 63 тиенне тәшкил итә.

Ел саен республикада Министрлар Кабинеты боерыгы нигезендә авыр тормыш хәлендә калган, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган 18 яшькә кадәрге балаларга, махсус учреждениеләрдә укучы балаларга республика бюджеты хисабыннан Яңа ел бүләкләре тапшырыла. Быел 14876 мең бала шундый Яңа ел бүләге алачак. Бер күчтәнәчнең бәясе – якынча 800 сум.

Чыршы, тәмле күчтәнәч һәм могҗиза

Гадәттәгечә, иң актив, сәләтле балаларны Президент чыршысында көтәләр. Быел ул 25 декабрьдә узачак. Бу юлы гаилә, могҗизага ышану, рухи кыйммәтләр турында тамаша көтелә. Чыршы бәйрәменең үзенчәлекләре турында Татарстанның яшьләр эшләре буенча министры Тимур Сөләйманов сөйләде.

– «Татнефть Арена» боз сараенда традицион республикакүләм Чыршы бәйрәме узачак. Бәйрәмгә 8,5 меңләп бала чакырулы. Алар арасында авыр тормыш хәлендә калган, сәламәтлеге чикләнгән, ятимнәр, күпбалалы гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр дә бар. Чыршы бәйрәменә спортта, мәктәп тормышында активлык күрсәткән, сәләтле балалар да килә. Шул исәптән быел мобилизацияләнүчеләрнең балаларын да кунакка көтәбез, 2 мең бала чакырулы, – диде министр. – Тамаша да гаилә традицияләре һәм мәңгелек кыйммәтләр турында булачак. Традиция буенча, балаларны котларга Татарстан Президенты да киләчәк. Чара 11.30 сәгатьтә башлана. Бәйрәмгә килүчеләрне тәмле күчтәнәч һәм йомшак уенчык көтә.

Тимур Сөләйманов балалар өчен ял һәм сәламәтләндерү лагерьлары эшчәнлегенә дә тукталды. Кышкы каникул чорында Татарстанның 21 районында урнашкан 64 сәламәтләндерү оешмасында 4,2 меңнән артык бала ял итәчәк. «Моннан тыш, 28 декабрьдән Кырымда «Ак Барс» исемле яңа лагерьда смена оештырылачак. Анда ел дәвамында үзләрен актив итеп күрсәткән зур яшьләр берләшмәләре студентлары һәм лидерлары ял итәчәк», – диде министр.

Эчтә дә, тышта да – бәйрәм

Балалар ялы аңлашылды. Ә зурларга нишләргә? Гомумән, гаилә белән ял итү өчен кая барырга була? Башкала мэриясе һәм Мәдәният министрлыгы бу сорауга җавапны белә.

Казан башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов сүзләренчә, шәһәрдә 170ләп чара оештырылачак. Бу әле ачык һавадагылары гына. Моннан тыш мәдәният, яшьләр сәясәте һәм белем бирү оешмаларында 400ләп чара оештыру ниятләнә.

Шәһәрнең төрле мәйданчыкларында чыршы утлары да кабына башлады. Ә төп чыршы – «Казан» гаилә үзәге янындагысы инде бүгеннән үк якты утлары белән сөендерергә әзер.

Бездән киңәш тә шул: шәһәр мэриясе оештырачак чаралар исемлеге бик зур. Берсен дә игътибарсыз калдырмыйм, дисәгез, яңалыкларны рәсми сайттан күзәтеп барыгыз. Остаханәләр, Кыш бабайлы тамашалар, концерт, фестивальләр – Казан гөрләтәчәк әле!

Мәдәният министры Ирада Әюпова әйтүенчә, бәйрәм программасы төрле булачак. Министрлык хезмәткәрләре гаилә белән ял итә алырдай чараларга басым ясаган. Әйтик, музейларда, музей-тыюлыкларда – 100дән артык, театрларда – 200ләп, филармониядә шулай ук 100ләп чара булачак. Сүз уңаеннан, кышкы каникул чорында ташлама-акцияләрдән дә файдаланырга була. Моңа өстәп цирк, урам, парклардагы тамашаларны да исәпкә алырга кирәк.

Ирада Әюпова әйтүенчә, Казан Кремле территориясендә дә Яңа ел чыршысы утлары кабыначак. 22 декабрьдә беренчеләрдән булып чыршыга республикадан мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләрендә тәрбияләнүчеләрнең башлангыч сыйныфта укучы балалары соклана алачак. Берничә көн эчендә 2,2 меңләп бала килер дип көтелә.

Мәдәният министры халыкны өйдә утырмаска, ялларны йоклап, ашап, телевизор карап кына уздырмаска өндәде. Юкка тырышмыйлар бит инде. Оештыручылар әйтмешли, кесәгә дә, кәефкә дә ярарлык чараларны һәркем таба алачак.

Үз илеңдә эшлисе

Кайбер белгечлекләр буенча чит илдән торып эшләүне тыю турында закон проекты шушы көннәрдә Хөкүмәт каравына юлланачак. Шуннан соң документ Дәүләт Думасына кертеләчәк. Министрлар Кабинеты исә чит илләрдән дистанцияле эшләү тыелган белгечлекләрнең конкрет исемлеген билгеләргә тиеш, дип яза РБК.

Шул сәбәпле Россия Хезмәт кодексына төзәтмәләр кертеләчәк. Яңалык оборона, иминлек системасын тәэмин итү, финанс секторында һәм башка өлкәләрдә эшләүче белгечләргә кагылырга мөмкин. «Бердәм Россия» фракциясе җитәкчесе урынбасары Андрей Исаев әйтүенчә, бу кемнәрнедер кысуны күздә тоткан закон түгел. Биредә сүз халык иминлеге турында бара. Закон проектын сенатор Андрей Клишас тәкъдим иткән.

Узган атнада Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгында IT компанияләр хезмәткәрләренә чит илдән торып эшләүне тыюга каршы чыкканнар.

Бушлай булачак

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләре әгъзаларына республикада бушлай юридик ярдәм күрсәтү күздә тотыла. Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында депутатлар тиешле закон проектын хуплаган.

Документта, аерым алганда, мобилизацияләнүчеләрне, контракт буенча үз ихтыяры белән хезмәт итүчеләрне бушлай юридик ярдәм алуга хокуклылар исемлегенә кертү тәкъдим ителә. Бу хокук аларның ата-аналары, хатыннары, балаларына да кагылачак.

Кунаклар килә

Яңа ел каникулы чорында Татарстанга 170–180 мең чамасы туристның килүе күздә тотыла. Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов әйтүенчә, быел сәяхәтчеләр саны узган елдагыга караганда 10–11 процентка күбрәк булачак. Кунакханәләрдә дә «урак өсте» көтелә: озын ялларның күпчелек көннәрендә урыннар 95–97 процентка броньланган. Ә узган елда Яңа ел бәйрәмнәрендә бездә 140 мең кунак булып киткән икән. 2–9 гыйнвар көннәрендә кунакханәләр 90 процентка тулы булган.

Кыш бабайның Арча районы Яңа Кырлай авылындагы резиденциясенә сәяхәт республикада яшәүчеләр, шулай ук сәяхәтчеләр күңеленә бик хуш килә. Узган елда бәйрәм көннәрендә анда 3000 кеше булып киткән.

Сергей Иванов сүзләренә караганда, туристларның рекордлы санда көтелүе Европа илләренә юлның ябылуына да бәйле.

Чигенергә җыенмый

Соңгы тәүлектә Россиядә 5994 кеше ковид йоктырган. Коронавируска каршы көрәш буенча федераль оператив штаб мәгълүматларына караганда, пандемия башланганнан бирле илдә чир ияртүнең барлыгы 21728409 очрагы теркәлгән.

Илдә бер тәүлек эчендә 1564 сырхау хастаханәгә салынган. 57 кеше вафат булган. Гомумән алганда, пандемия башланганнан бирле 393107 сырхауның гомере өзелгән.

Шул ук вакытта илнең 86 төбәгендә «дуңгыз гриппы» таралган. Роспотребнадзорның матбугат хезмәте хәбәренә караганда, бер атна эчендә ОРВИ һәм грипп йоктыручылар саны 15,8 процентка арткан. Белгечләр әйтүенчә, вируслар арасында грипп вирусы (70% чамасы) өстенлек итә. Иң киң таралганы – «дуңгыз гриппы» вирусы.

Бердәмлек

Горурланырга бер сәбәп

Дус-тату яшәүгә ни җитә! Казан Кремлендә республикадагы милләтара һәм динара дуслык турында сөйләштеләр. Бу уңайдан, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов яшьләр арасында эшне көчәйтергә, ә тәрбияне балалар бакчасыннан ук башларга киңәш итте.

Башкалада Татарстан Президенты каршындагы милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча советның һәм Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уздыру буенча оештыру комитетының берләштерелгән утырышы узды. Чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Соңгы мәгълүматларга караганда, Татарстанда 173 милләт халкы яши. «Күпмилләтле республикабызда халыкларның дустанә мөнәсәбәте урнашкан. Һәр милләт халкы үз гореф-гадәтләрен, милли үзенчәлекләрен саклап яши», – диде Рөстәм Миңнеханов. Моның сере дә бик гади – Татарстанда бергә һәм бердәм булып яшәү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Бу уңайдан, Президент халык арасында үткәрелгән тикшеренү нәтиҗәләрен дә китерде. Баксаң, республикада яшәүчеләрнең 90 проценты Татарстандагы милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне уңай бәяли икән. Дус-тату яшәүгә ни җитә!

Мисал эзләп ерак барасы да юк. Утырышта чыгыш ясаган Яшел Үзән районы башлыгы Михаил Афанасьев сүзләренә караганда, алар үзләрендә чегән ансамбле оештырырга җыеналар. «Район халкының күпчелеген руслар (56 процент) һәм татарлар (40 процент) тәшкил итә. Башка милләт вәкилләре дә яши. Әйшә урта мәктәбендә, мәсәлән, 80гә якын чегән баласы белем ала. Алар яхшы билгеләргә укый, укытучылары мактап кына тора. Мәктәп тормышында да катнашалар, җырлыйлар-биилләр. Шуңа күрә райондагы 250ләп чегән җәмәгатьчелеге өчен аерым иҗат коллективы – чегән ансамбле төзү тәкъдиме бар», – дип сөйләде район башлыгы.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, Татарстанда яшәүче халыклар бай тарихи-мәдәни мираска ия. Безгә рухи кыйммәтләрне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләрне саклау, аларны киләсе буыннарга җиткерү мөһим. Бу юнәлештә былтыр – Россия халыкларының Мәдәни мирас елында шактый эш башкарылган инде. «Татарстанда узган ел мәдәни мирасыбызны саклау һәм үстерүгә бәйле 60тан артык зур чара узды. Аларны үткәрүгә 189 миллион сум акча тотылды», – дип сөйләде Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева. Илнең 48 төбәгендә, шулай ук 21 чит илдә 277 Сабантуй мәйданы гына гөрләгән. Үз гореф-гадәтләребезне саклап кына калмыйча, башкаларга да өйрәтәбез. «Сабантуйда төрле милләт халыклары рәхәтләнеп күңел ача», – диде вице-премьер.

Быел Татарстанда узган тарихи вакыйга – Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына да аерым тукталдылар. «Бу уңайдан үткәрелгән чаралар югары дәрәҗәдә узды. Бу олы вакыйга ислам диненең мәдәни мирасны формалаштыруын, төрле дин вәкилләренең үзара хөрмәттә яшәвен тагын бер кат раслады. Бу – безнең бәяләп бетергесез байлыгыбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Максут ШАДАЕВ, цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры:

Күптән түгел генә булган «эмиграция»нең ике дулкынына бәйле рәвештә йөз мең чамасы IT белгеч Россиягә кайтмаган. Аларның 80 проценты барыбер дустанә илләрдә яшәп, Россия компанияләрендә эшләвен дәвам иттерә. Айтишникларны кире кайтару өчен, читтән торып эшләүне тыюдан баш тартырга кирәк. Әгәр мондый чара кертелсә, бу белгечләрнең чит ил компанияләренә тизрәк эшкә урнашуына китерәчәк.

(«Парламентская газета»дан)

ТАТАРСТАНДА – МИЛЕК

Быел Татарстанда яшәүчеләр 87 мең ипотека рәсмиләштергән. Узган ел белән чагыштырганда электрон ипотека саны арткан (75 процентны тәшкил итә).

БЫЕЛ САТЫП АЛЫНГАН

95 мең җир кишәрлеге

17 мең шәхси торак йорт

79 мең торак бина

8 мең торак булмаган бина

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГАЗЛЫ КӨРӘШ

Европа берлеге илләре «түшәм» төзү белән мавыга башлады: нефть бәясенә чикләү керткәннән соң зәңгәр ягулыкка да чират җитте. Анысы 2023 елның 15 февраленнән гамәлгә керә. «Түшәм»нең биеклеге 1 МВт. сәгатькә 180 еврога тигез, без кулланып өйрәнгән үлчәүдә мең кубометры 2 мең доллар дигән сүз.

Мондый чикләү газ бәясе Европаның иң зур хабы булган TTF газ саклагычында өч көн рәттән шул дәрәҗәдән узып китсә җаеләчәк. Аның биекме, юкмы икәнен карау өчен, бүгенге бәягә күз төшерергә кирәк. Автор 20 декабрь иртәсендә TTF биржасының котировкаларын карады. Газга бәя – мең кубометрга 1165,35 доллар. Моннан нәкъ ике ел элек шул ук голланд хабында газның мең кубометры 199,7 долларга сатылган һәм бу югары бәя булып исәпләнгән. Саннарны калькуляторга салабыз да 5,83 дигән сан алабыз, ягъни газга бәя ике ел эчендә шул чаклы үскән. «Түшәм» исә ун тапкырдан да артыграк бәядән куелган. Күрәбез: бик югары җәйгәннәр такталарны. Әгәр Россия Көнбатышка шул бәядән элекке күләмдә газ сатса һәм кергән акча тиешенчә тотылса, без алтынга манчылыр идек.

Вазгыять исә хәзер шундый: европалылар 2 мең долларны да түзәрлек бәя дип саный. Ул гына да түгел, газга «түшәм» кую зәңгәр ягулыкның Европа базарын ташлап китеп, Азиягә таба агылуыннан куркалар. Әйтик, азиатлар тагын да югарырак бәя түләсәләр, Европаның газсыз калуы ихтимал. «Ирекләр», «базар икътисады» дип лаф орган Көнбатыш үз кагыйдәләрен үзләре үк бик тиз боза башлады. Мөгаен, февральгә ягулык бәясе космик тизлек белән күккә омтылыр дип куркалардыр.

Россия хәзер газны нинди бәягә сата дигән сорау туа бит инде. Көзен Төркиягә мең кубометрын 600–700 доллардан озаткан. Россия белгечләре 500 доллар да табышлы дип саныйлар. Төрекләр 25 проценттан да зуррак ташлама таләп итә һәм үз дигәннәренә ирешерләр кебек. Шуңа өстәп тагын Әнкара түләүне кичектереп торуны да сорый. Европага күпләп газ сату мөмкинлегеннән колак какмаган булсак, «түшәм»нән күпкә түбәнрәк бәя дә безнең өчен менә дигән буласы. Әмма Россия генә түгел, көнбатышлылар үзләре дә базарның асты өскә килүеннән бик интегә. Германия, мәсәлән, энергетик кризиска каршы тору өчен 440 миллиард евро акча тотарга мәҗбүр. Бу – бер көнгә 1,5 миллиард, кеше башына (балаларны да кертеп) 5400 евро дигән сүз. Германия икътисадында барлык җитештерелгәннең 12 процентына тиң. Тагын бер сан китерә алабыз: пандемиягә каршы көрәшкә немецлар 2020 елда 480 миллиард доллар акча тотканнар. Хөкүмәт тоткан акча энергетика компанияләрен бөлгенлектән саклау өчен кирәк. Газ «түшәм» бәядән сатыла башласа, күпме субсидия таләп ителәсен исәпләүчеләр әлегә күренми.

«Түшәм» бик биек булса да, газ сатучы биржалар аннан канәгать түгел. TTF хабының хуҗалары, чикләү кертелсә, газ саклагычны Европа берлеге чикләреннән читкә чыгару белән яныйлар.

Россиядә

СУМ БАТКАНДА, ДОЛЛАР КАЛЫККАНДА

Дүшәмбедә биржаларда доллар һәм евро сум өстеннән тантана итте. Сәгать саен диярлек сумның түбәнәюе, резерв валюталарның кыйммәтләнүе турында хәбәрләр килеп торды. Көнне 68 сумлык доллар һәм 72 сумлык евро белән төгәлләдек.

Сишәмбе иртәсендә биржалар ачылганда да хәл шундый ук иде: доллар – 68 сум тирәсе, евро – 72,3 сум. Евросоюз валютасы берара бик очсызланып, долларга караганда да арзанаеп алган иде, аннары янә югары калыкты. Россия федераль хөкүмәтенең хыялы тормышка аша башлады. Финанс министрлыгы сумны йомшарту теләге белән күптән яна иде инде. Арзанлы сум бюджет өчен файдалы. Халык өчен шәп түгел, әлбәттә, бәяләрнең югары күтәрелүен вәгъдә итә.

Мәскәүдә басылган акчаның кыйммәте югалуда берничә фактор «гаепле». Бердән, нефтькә бәяләр төште. Россия исә «кара алтын»ны зур дисконт белән сатарга мәҗбүр. Ташлама шул дәрәҗәгә җитә: кайбер очракларда читкә озаткан нефтьнең бәясе үзкыйммәте белән тигезләшә, табыш керми. Азия белән сәүдә иткәндә доллар түгел, милли валюталарны куллану да үз сүзен әйтә.

Рецессия чимал бәяләрен түбәнгә этә. Нефтькә генә түгел, башка материалларга да хак очсызлана. Россия исә нигездә шундый очсызлана торган чимал гына сата. Көнбатышның Үзәк банклары рецессиягә китерә һәм резерв валюталарын кыйммәтләндерә торган чаралар күрде: процент ставкаларын күтәрделәр. Бу, бердән, кредитларның кыйммәтләнүенә һәм шул сәбәпле бизнесның артка чигүенә китерә. Икенчедән, фонд базарлары түнә һәм спекулянтлар кыйммәтле кәгазьләрен валютага алыштыру юлын сайлый. Долларга күп процент вәгъдә ителү сәбәпле, башка илләрдән дә валюта Америкага агыла башлый. Әле генә доллардан баш тартабыз дип кычкыручыларга Америка кәгазьләре кыйммәтле булып тоела. Федераль резерв системасы 2023 елда да төп ставканы күтәрү юлыннан барырга ниятли. Фаразлыйбыз: бу долларның тагын да кыйммәтләнүенә китерер. Һәм... берочтан АКШ икътисадын да рецессиягә тартып кертер. Глобаль икътисадта бик күп чылбырлар үзара бәйләнгән. АКШ рецессиясе Кытай базарында да һәм башка мәйданнарда да түбәнәю китереп чыгарачак. Күңелсез булмас, кыскасы.

Сумның көчсезләнүенә Россия Үзәк банкы күп итеп баскан акча да үз өлешен кертә. Яңа гына бер триллион сум басып, банкларга репо итеп өләштеләр. Югарыда шундый карусель әйләнә инде, ахыр чиктә яңа акчаның бер өлеше долларга алыштырыла.

Автор кризисны компьютер өстәле янына утырган хәлдә үз җилкәсендә татый. Хатын – кибеттә, телефонга, чыелдап, ул тоткан акча турында хәбәрләр ява. Әмма күтәрешеп кайтырга каршы барасы юк. Бик авыр булмый сумкалары. Ресторан бизнесы тирән кризиста, дигән хәбәр дә алдым. Көз дәвамында оешмаларның 10 проценты ябылган. Сәбәбе: продуктлар кыйммәт, ресторанга йөрүчеләр аз.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ЯРАТУ ҺӘМ ТАНУ

Кичә Рөстәм Миңнеханов Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшырды. Рөстәм Миңнеханов чыгышында узып баручы елның җиңелләрдән булмавын искәртте. «Илкүләм лидерыбыз Владимир Путин тирәсендә тупланып, без авырлыкларны бергә җиңеп чыгабыз, туган Татарстан һәм илебез өчен нәтиҗәле эшләвебезне дәвам итәбез», – диде Президент.

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов республика халкы, предприятиеләре һәм иҗтимагый оешмаларның махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм оештыруда актив катнашуын да билгеләп үтте. «Без бу яхшы эшкә өлеш керткән һәркемгә рәхмәтле», – диде Татарстан Президенты. Татарстанның тотрыклы үсештә булуын, Россия төбәкләре арасында алдынгылыкны саклавын да искәртте. «Бүген без республика үсешенә һәм халыкның тормыш сыйфатын арттыруга мөһим өлеш кертә торган сәнгать, бизнес һәм социаль өлкә вәкилләрен хөрмәтлибез», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов фән, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренә, шул исәптән дирижер Анатолий Шутиковка, шагыйрь Газинур Моратка, артистка Гөлшат Шәрәповага аерым рәхмәт белдерде. «Әлбәттә, сезнең талантыгызны һәм осталыгыгызның иң яхшы дәлиле – татарстанлыларны ярату һәм тану», – диде Татарстан Президенты.

Дәрәҗәле бүләккә лаек булуы белән котлап, Г.Тукай премиясе иясе, шагыйрь һәм публицист Газинур Моратның үзе белән элемтәгә кердек.

– Бүгенге дәүләт бүләген тыйнак кына иҗатыма бирелгән зур бәя дип кабул итәм. Мең елдан артык тарихы булган татар әдәбиятының күп кенә чорын без поэзия аша күзаллыйбыз. Шушы поэзиябезнең кечкенә генә бер кисәкчеге, дәвамы булып яши алуымны бик зур мәртәбә дип саныйм. Ана телебездә аралашып, уйлап яшәү, иҗат итү – шулай ук күкләрдән иңдерелгән бүләк. Киләчәктә дә шул рәвешле яшәргә, иҗат итәргә язсын, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасында Рөстәм Миңнеханов киләсе елның республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителүен дә искәртте. «Татарстанның бай тарихи-мәдәни мирасы, милли традицияләре бар. Безнең кунакчыл республикада төрле милләт вәкилләре тату һәм дус яши. Хакимият органнарының, киң җәмәгатьчелекнең һәм бизнес-җәмәгатьчелекнең уртак тырышлыгы белән киләсе ел яхшы эшләр һәм уңай нәтиҗәләр белән баетылыр, дип ышанам», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент кулыннан дәрәҗәле бүләк алган «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге җитәкчесе Маринэ Хухунашвили да төрле милләт һәм дин вәкилләренең дустанә яшәвен республиканың зур казанышы дип саный:

– Без һәрчак республика җитәкчелегенең ярдәмен тоеп яшибез. Республикада алып барылган шушы сәясәт нәтиҗәсендә Татарстанда төрле милләт һәм дин вәкилләре ничә дистә еллар, гасырлар буе дус-тату, иминлектә яши. Мин 25 ел җитәкләгән «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» дә әнә шушы мирасны киләчәк буыннарга тапшыруны максат итә. Иң мөһиме шул: безнең республикада барлык милләт вәкилләре дә бертигез, барыбызга да бер үк төрле шартлар тудырылган. Минем үз язмышым да моның ачык мисалы булып тора. Тумышым белән Татарстаннан булмасам да, республика өчен башкарган күпъеллык хезмәтемне әнә шулай югары бәяләделәр. Татарстан халыклары ассамблеясы дип аталган бердәм, дус гаиләбезнең уртак бүләге бу.

ЯСАЛМА АКЫЛ ГЫНА ТҮГЕЛ, ЗАМАНЧА БЕЛГЕЧ ТӘ КИРӘК

Авыл хуҗалыгында саллы уңышларга ирешү өчен техник яктан үзгәртеп кору, акча белән тәэмин итү, инновацион технологияләр кертү генә аз. Аны кадрлар белән тәэмин итү дә мөһим. «Татарстан – Яңа Гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәте Югары советы утырышында шундый фикер әйтелде. Авыл хуҗалыгы өчен белгечләр әзерләү мәсьәләләренә багышланган утырыш Казан дәүләт аграр университетында узды. Хәрәкәт әгъзалары бу елдагы эшкә йомгак ясап, киләсе чорга планнарын да раслады. Утырышны Дәүләт Советы Рәисе, «ТЯГ» Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин уздырды.

Чараның Россиядәге иң өлкән вузларның берсендә (быел КГАУ 100 еллыгын билгеләп үтте) үткәрелүе очраклы түгел. Шушы вакыт эчендә биредә авыл һәм урман хуҗалыклары өчен 40 меңгә якын белгеч әзерләнгән.

«Югары квалификацияле кадрлар – республикада агросәнәгать комплексын алга таба нәтиҗәле үстерүнең нигезе, – дип басым ясап әйтте Фәрит Мөхәммәтшин. – Соңгы елларда авыл хуҗалыгы, азык-төлек һәм эшкәртү сәнәгатьләре икътисадый үсешнең этәргеч көчләренә әйләнде. Өстәвенә биредә сүз илнең азык-төлек иминлеген тәэмин итү турында да бара».

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Татарстан өчен агросәнәгать комплексы икътисадның төп тармакларыннан берсе (төбәк тулай продуктының 10 проценттан артыграгын бирә) булып тора. Республиканың авыл хуҗалыгы Россиядә алдынгы сафларда бара (сөт җитештерү буенча – беренче, бәрәңге буенча – икенче, ит буенча – алтынчы, йомырка җитештерү буенча – җиденче урында). Быел рекордлы уңыш – 5 миллион тоннадан артык ашлык җыеп алынган.

Дәүләт Советы Рәисе билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта авыл хуҗалыгы югары технологияле индустриягә әйләнеп килә. Күп кенә эшләр автоматлаштырыла, цифрлы технологияләр, ясалма акыл системасы һәм башкалар кертелә. «Әмма алга таба уңышларга ирешү өчен техник яктан үзгәртеп кору гына түгел, кадрлар белән тәэмин итү дә бик мөһим», – дип билгеләп үтте Дәүләт Советы Рәисе. Аның фикеренчә, вузны тәмамлап чыгучылар иң алдынгы белемнәргә ия булып, аларны тормышта куллана алсыннар өчен аграр белем бирүне заманчалаштырырга кирәк.

«ТЯГ» иҗтимагый хәрәкәте әгъзалары утырышта билгеләп үткәнчә, бүген урта һәм югары белем бирү оешмаларында авыл хуҗалыгы белгечләрен әзерләү куелган таләпләргә тулысынча җавап бирми. Чарада катнашучылар, шуны истә тотып, Татарстан Мәгариф һәм фән, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыкларына табигый-фәнни һәм инженерлык юнәлешләрендәге «Агрокласс» профильле сыйныфлар булдыру эшен киңәйтү тәкъдиме белән чыкты. Моннан тыш Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына «Агросәнәгать комплексында хезмәт базары навигаторы» цифрлы платформасын булдыру мәсьәләсен өйрәнү тәкъдим ителде. Анда авыл хуҗалыгына белгечләр әзерләү юнәлешләре, вакансияләр, практикалар узу базалары турында укучылар, студентлар, ата-аналар, авыл хуҗалыгы предприятиеләре өчен мәгълүматлар урнаштырырга мөмкин булачак.

Спорт сагындырган, уку ялыктырган

Барлык мәктәпләрдә спорт клублары булдырырга! 2023 елга Мәгариф һәм фән министрлыгының өстенлекле юнәлешләрен билгеләүгә багышланган сораштыруда халык иң күп тавышны (49,3 процент) шуңа биргән.

Икенче урынга югары уку йортларын тәмамлаучыларны эшкә урнаштыру мәсьәләсе чыкса, өченчедә – эшче профессияләргә бәйле программаларның санын арттыру.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет утырышында белгечләр сораштыру нәтиҗәләрен игълан итеп, киләсе елга мәгариф өлкәсендәге бурычларны билгеләде. Әлеге тармактагы мөһим мәсьәләләрне ачыклау өчен, халык арасында онлайн тавыш бирү уздырылган иде. Җәмәгатьчелеккә барлыгы 15 юнәлеш тәкъдим ителгән. Сораштыруда 4 меңнән артык кеше катнашкан.

– Ел ахыры бик киеренке: бу көннәрдә бик күп чаралар үтә. Мәгариф тармагына һәрвакыт зур урын бирелә. Бүген районнарга 50 автобус тапшырачакбыз, – диде утырышта катнашкан мәгариф һәм фән министры урынбасары Станислав Андреев. Аннан ул онлайн сораштыру нәтиҗәләренә тукталды. Мәктәпләрдә спорт клублары булдыру ихтыяҗының беренче урынга чыгуы урынбасарны да, белгечләрне дә бераз гаҗәпләндерде. Моңа Станислав Андреев үзе үк ачыклык кертеп: «Сер түгел, бүген укучыларның сәламәтлеге нык түгел. Шуңа күрә аларны көчле шәхес итеп тәрбияләүгә җитди игътибар бирергә кирәк», – диде.

Сораштыруда катнашучыларны укучыларның сәламәтлеге генә түгел, рухи ягы да кызыксындыра. Алар мәктәпләрдә балаларның рухи халәтен ныгытуга бәйле чараларны даими уздыру яклы. Шуңа әлеге юнәлеш дүртенче баскычта да инде. Шулай ук җәмәгатьчелек фән, технология өлкәсенә дә битараф түгел. Респондентлар әлеге тармакта өстенлекле юнәлешләр буенча тикшерүләр уздыру, эшләнмәләр булдыруга акчаны кызганмау, елга 50дән дә ким булмаган яшь галимгә грантлар бирүне мөһим дип саный. Авыру балалар темасы да читтә калмаган. Махсус оешмаларда җиһазларны яңарту, балалар бакчаларында сабыйлары авырган әти-әниләр өчен киңәшләр бирүгә дә халык аз тавыш бирмәгән. Ә менә математика, химия, астрономия һәм башка фәннәрдән олимпиада җиңүчеләрен арттыру, туган телләргә бәйле конкурсларда катнашучыларның санын 9 меңнән 10 меңгә җиткерү кебек сорауларга әллә ни исләре китмәгән. Иҗтимагый совет утырышында халык иң күп тавыш биргән 7 юнәлеш сайлап алынды.

Шул ук вакытта 600ләп кеше үз фикерен калдырган. Алар арасында мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакын, белем сыйфатын арттыру, түгәрәкләргә йөрүне бар балага да кулай итү, укытучыларның кәгазь эшен киметү, укучыларга психологик ярдәм күрсәтү, биш көнлек укытуга, бер генә сменага күчү, БДИны реформалаштыру дигәннәре дә бар. «Гомуми фикерләр булса да, болар халыкка, укытучыларга, әти-әниләргә бик мөһим», – диде Станислав Андреев.

Сораштыру нәтиҗәләре сүздә генә калмаячак. Иҗтимагый совет рәисе Асия Тимирясова киләсе елда бу бурычларның үтәлешен контрольгә алырга туры киләчәген искәртте.

Сәрия МИФТАХОВА

Алсу Камалованың шәхси архивыннан

АЛСУ КАМАЛОВА: «МОДАДА – ТАБИГЫЙЛЕК»

«Минем өчен үземнең һәм гаиләмнең сәламәтлеге мөһим». Сарманда яшәп, экологик чиста һәм зарарсыз булган чистарту чаралары җитештерүче Алсу Камалова әлеге эшкә тотынуының сәбәбен әнә шулай дип аңлата. Әлеге мавыгуы кечкенә кызы белән декретта утырган вакытта башлана.

– Экологик чиста ризык, көнкүреш кирәк-ярагы турында бала булгач, тагын да ныграк уйлый башлыйсың икән. Хәер, миндә ул бала туганчы ук формалаша башлаган иде. Шуңа күрә бәби алып кайтканчы ук мондый төр продукция белән кызыксына башладым. Ләкин кибетләрдә аны табу авыр, булганы да бик кыйммәт. Шулай ук намуссыз эшләүчеләр дә очраштыргалады, – дип аңлатты ул үзенең әлеге һөнәргә алып килү юлын.

Шулай итеп Алсу экологик чиста көнкүреш продуктларын ясарга ниятли. Иң элек ул рецептлар әзерләүче Ильмира Исмәгыйлева дигән белгечнең социаль челтәрләрен кызыксынып күзәтә. Бераздан аның курсларына языла. Акрынлап үзе дә продуктлар ясый башлый, ә ныклап торып эшләп китүе узган елның маена туры килә. Башта экологик чиста һәм зарарсыз чистарту чараларының чималларын табу белән авырлыклар була, ләкин тора-бара анысы да җайлана. Кыскасы, бүген Алсу плитә, ванна, савыт-саба юа, кием агарта, кухня гарнитурын, суыткычларны һәм башка өслекләрне чистарта торган универсаль юу чараларын ясый.

– Барысы бергә 22 рецептым бар, ягъни шуның кадәр ясау мөмкинлеге бар, ләкин әлегә мин халык аеруча күп сорый торган җиде төрле чистарту чарасын эшлим. Йортлары янында гына бар уңайлыклары булган бүлмә дә ясап куйганнар.

– Шәхси эшмәкәр булып теркәлдем. Ниндидер бина арендалап та эшләргә мөмкин булыр иде, тик Сарманда бар уңайлыклары булган бина табу җиңел түгел, шуңа күрә әлегә менә шушында урнаштым. Бер төрле юу чарасын ясар өчен 3–4 сәгать вакыт кирәк. Гадәттә бер ясаганда 20ләп данә эшлим, – диде ул.

Алсу үзе җитештергән продуктын төрле кибетләр аша сата икән. Киләчәктә эшен җәелдереп, маркетплейсларга чыгу планы да бар. Әйтергә кирәк, бәяләре дә чын экологик продуктлар белән чагыштырып караганда арзанрак.

– Иң сөендергәне – кешеләрнең табигыйлеккә тартылуы, химия кушып эшләнгән әйберләрдән читкәрәк китүе. Сайлау мөмкинлеге булгач, теләп алалар. Мин ясаган продуктка да сорау зур. Бердән, алар зарарсыз булса, икенчедән, нәтиҗәсе бар. Эшемнең иң зур канәгатьлек китерә торган өлеше – ул халыктан килгән кайтавазлар, – ди яшь эшмәкәр.

Район үзәгендә, авылда яшәп тә, яңа төрле һөнәрләргә өйрәнеп була, дип саный Алсу. Баштагы вакытларда үзендә курку, шикләнү булса да, тәвәккәлләп кереп киткәч, эшеннән бик канәгать булуын әйтте.

– Һөнәрем буенча мин – укытучы, ләкин мәктәптә укытканым булмады. Никтер күңелем шушы тармакка күбрәк тартылды. Эш башлаганда ниндидер ерак шәһәрләргә җибәрермен, дип уйламаган да идем. Ә хәзер минем продуктлар Дагыстан Республикасына, Мәскәүгә күп китә. Кешеләргә файдалы була алуым белән бәхетлемендер, дип уйлыйм. Зарарлы ризыклар, химия тормышта болай да күп, мөмкин булганча экологик чиста продукт куллансак иде дип телим, – диде Алсу Камалова.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ИСКЕЧӘ ИСӘПЛӘП, ЯҢАЧА ТҮЛИЛӘР

Киләсе елның 1 гыйнварыннан бала тәрбияләүче гаиләләргә яңа төр пособие гамәлгә керәчәк. Әти-әниләрнең айлык акчасы артачак дип тә фаразлыйлар. Бердәм пособиегә кемнәр өмет итә ала? Әлеге төр түләү ничек билгеләнә? Бу хакта Россия Пенсия фондының Татарстандагы бүлеге идарәчесе Эдуард ВАФИН белән сөйләштек.

:: Эдуард Яфасович, бердәм түләү нәрсәдән гыйбарәт?

– Яңа бердәм пособие 17 яшькә кадәр бала тәрбияләүче аз керемле гаиләләргә һәм йөкле хатын-кызларга кагыла. Ул моңа кадәр гамәлдә булган барлык төр түләүләрне берләштерәчәк. Шул рәвешле, йөклелек чорыннан алып балага 17 яшь тулганчы гаиләләргә ярдәм күрсәтүнең эзлекле системасы барлыкка киләчәк.

Бердәм пособие гамәлгә кергәч, түләү алу өчен документлар тапшыру тәртибе дә җиңеләячәк. Ягъни хәзерге кебек 3 яшькә кадәр, 3–8 яшь, 8–17 яшьлек балаларга пособие алу өчен аерым-аерым документлар тапшыруның кирәге калмаячак. Бөтен балага бер гариза да җитә.

:: Яңалык гамәлгә кергәч, пособие билгеләүнең кагыйдәләре үзгәрәме?

– Юк. Бүген 3–7 яшьлек, 8–17 яшьлек балаларга түләү билгеләүдә нинди кагыйдәләр гамәлдә булса, алга таба да шулай булачак.

Пособие билгеләүнең беренче шарты – ул гаиләнең керем дәрәҗәсе. Матди ярдәм аз керемле гаиләләргә билгеләнә. Гаиләнең уртача айлык кереме Татарстанда җан башына билгеләнгән яшәү минимумыннан артып китмәскә тиеш. Киләсе елда әлеге күрсәткеч 12219 сум тәшкил итәчәк, дип фаразлана.

Икенчедән, пособие билгеләгәндә гаиләнең милке исәпкә алына. Бүген 8–17 яшьлек бала тәрбияләүче гаиләләргә түләү билгеләгәндә нинди кагыйдәләр гамәлдә булса, алга таба да шулай ук калачак. Кыскасы, күчмә һәм күчемсез милеккә бәя биреләчәк.

Өченчедән, пособие әти-әниләрнең керемнәре расланган очракта гына түләнә. Моңа хезмәт хакы, стипендия һәм башкалар керә. Ягъни «керем нуль» кагыйдәсе исәпкә алына. Әгәр әти-әнинең берәрсе эшләми икән, моңа җитди сәбәп булырга тиеш. Мондый очракта пособие түләнә. Алдан ук ачыклык кертик: хезмәт хакларына бәя биргәндә, керем чоры 12 айга бүлеп исәпләнә. Әти-әнинең берәрсе шул 12 айның бер көнендә дә эшләмәгән икән, ким дигәндә 10 ай буе эшләмәүнең сәбәпләрен аңлатып бирергә туры киләчәк.

:: Әгәр кеше шушы 12 ай эчендә бер ай рәсми рәвештә эшләсә, аңа пособие тиешме?

– Пособие алырга теләүче турындагы мәгълүматны башка ведомстволар аша тикшерәчәкләр. Бу очракта Социаль фонд, ә 2023 елның 1 гыйнварыннан Россия Пенсия фонды һәм Социаль иминият фонды берләштерелгәч, ул әнә шулай аталачак, гариза тапшыручы турындагы мәгълүматны Салым федераль хезмәтеннән белешәчәкләр. Бер ел эчендә берәр төрле керем алуы расланса, ул эшмәкәрлеккә яки үзмәшгульлеккә бәйле булырга да мөмкин, мондый кешегә «керем нуль» кагыйдәсе кулланылмый.

:: Керем булмауга җитди сәбәп булырга тиеш, дидегез. Бу хакта төгәлрәк аңлатсагыз иде. Кайсы очракта әти-әниләргә, эшләмәсәләр дә, пособие түләнәчәк?

– Керемнәрне раслап күрсәтү таләп ителмәгән очракларга аерым тукталыйк:

✓күпбалалы гаиләдә әти-әнинең берсе бала караган очракта, тик әти-әнинең икенчесе хезмәт, эшмәкәрлек, иҗади эшчәнлек, пенсия, стипендия һәм башкасына бәйле керемнәрен раслап күрсәтергә тиеш;

✓баланың әтисе яки әнисе генә булып, ул бала караган вакытта керемнәрне дәлилләп күрсәтергә кирәкми. Сүз рәсми рәвештә ялгыз бала тәрбияләүчеләр, баланың әтисе яки әнисе үлү, туу турындагы таныклыкта күрсәтелмәү яки хәбәрсез югалучылар турында бара;

✓өч яшькә кадәр бала тәрбияләү;

✓18 яшькә кадәр инвалид бала тәрбияләү, балачактан I төркем инвалид тәрбияләү, I төркем инвалид тәрбияләү, дәвалау учреждениесе белешмәсе нигезендә даими караучы таләп ителгән карт кешене карап тәрбияләү яки 80 яшьтән өлкән кешене тәрбияләү;

✓23 яшь тулмаган гаилә әгъзалары көндез белем алган очракта;

✓хәрби хезмәттә булган вакыт һәм армиядән кайтканнан соң 3 ай;

✓3 ай һәм аннан да күбрәк дәваланган очракта;

✓эшсезлек чоры, бу очракта мәшгульлек үзәгендә рәсми рәвештә эшсез буларак теркәлү турындагы документ кирәк булачак, ул 6 айга бирелә;

✓төрмәдә утырган вакыт һәм аннан чыккач 3 ай;

✓6 айдан яки айлык түләүгә гариза тапшырган көннән 12 атнадан йөклелек чоры;

✓гариза тапшыручы яки аның гаилә әгъзалары аз санлы Себер халкына кергән очракта.

2023 елның 1 гыйнварыннан керемнәргә бәйле кайбер үзгәрешләр дә гамәлгә керәчәк. Моңа кадәр баласы авырып өйдә утырырга мәҗбүр булган әти-әниләрдән, эшләмәсәләр дә, керемнәре турында белешмә сорыйлар иде. Яңа елдан мондый гаиләләр, бала өч ай һәм аннан да күбрәк өзлексез дәваланган очракта, керемнәре турында хисап бирүдән азат ителәчәк.

:: Бердәм пособие кертелүгә бәйле тагын нинди үзгәрешләр бар?

– Гаиләнең керем дәрәҗәсен билгеләү өчен исәпкә алына торган вакыт аралыгы үзгәрәчәк. Хәзер, мәсәлән, 8дән 17 яшькә кадәр бала тәрбияләүчеләргә пособие билгеләгәндә, без гариза биргән айдан 4 айга артка чигенеп, 12 айлык керемне исәпкә алсак, киләсе елдан 1 айга гына артка чигенә башлаячакбыз. Гаиләдә җан башына туры килгән керемне билгеләү өчен 12 айлык хезмәт хакын кушарга, килеп чыккан санны 12гә һәм гаилә әгъзалары санына бүләргә кирәк.

Ана капиталыннан айлык түләүгә бәйле үзгәрешләр дә бар. Алга таба керемнәре җан башына ике яшәү минимумыннан да түбәнрәк булган гаиләләр, сабыйның гаиләдә ничәнче булып тууына карамастан, балалар өчен яшәү минимумы күләмендә айлык түләүгә өмет итә алачак. Хәзер мондый түләү икенче балага гына каралган. Түләүне билгеләү шарты шул ук – гаиләнең кереме Татарстанда җан башына ике яшәү минимумыннан да артмаска тиеш. Киләсе елда әлеге күрсәткеч 24438 сум (җан башына яшәү минимумы 12219 сум булган очракта. – **Ред.**) тәшкил итәчәк, дип фаразлана.

> Яңа төр пособие гамәлгә кергәч, өч яшькә кадәрге балаларга пособие алучылар артачак. Чөнки әти-әниләр берьюлы ике түләүгә – бюджеттан һәм ана капиталы акчасына өмет итә алачак. Бу очракта, киләсе елдан Татарстанда бер балага ярдәм күләме 23704 сум тәшкил итәчәк. Бердәм пособие һәм ана капиталыннан түләүгә гаризаны 2023 елның 1 гыйнварыннан тапшырырга мөмкин. 17 яшькә кадәрге балаларны бер гаризада күрсәтергә дә ярый.

Тагын бер яңалык йөклелекнең иртә срогында исәпкә баскан хатын-кызларга кагыла. Бүген булачак әниләр эшкә сәләтле кешеләр өчен яшәү минимумының яртысына тиң пособиегә өмет итә ала. Киләсе елдан йөкле хатын-кызлар гаиләнең керем дәрәҗәсенә карап, төбәктәге эшкә сәләтле кешеләр өчен яшәү минимумының 50, 75, 100 проценты кадәр пособие ала башлаячак. 2023 елда эшкә сәләтле кешеләр өчен яшәү минимумы 13319 сум тәшкил итәчәк, дип фаразлана.

Булачак әниләргә пособие йөклелекнең 12 атнасыннан соң аның мөрәҗәгате нигезендә билгеләнә. Ул медицина оешмасына исәпкә баскан айдан алып, әмма йөклелекнең 6 атнасыннан да иртәрәк түгел, бала тапкан айга кадәр түләнә. Бу – якынча 8 ай дигән сүз.

:: Элеккеге кагыйдәләр буенча балага пособие алучы гаиләләргә нишләргә? 1 гыйнвардан бердәм пособие рәсмиләштерергәме, әллә инде документларны яңадан тапшыру вакыты җиткәнне көтәсеме?

– Бала 2022 ел ахырына кадәр туса һәм инде пособие рәсмиләштерелгән булса, әти-әниләр түләү алуның ике юлын сайлый ала. Акча элеккеге кагыйдәләр буенча ничек бар, шулай түләнәчәк. Теләге булганнар бердәм пособиегә гариза җибәрә ала. Ничек кенә булмасын, гаилә үзенә отышлы булган түләүне алачак.

:: Димәк, бердәм пособие алганда гаиләдәге 17 яшькә кадәрге балаларга бер генә гариза тапшырырга кирәк булачак. Ә аларга түләү бер үк дәрәҗәдә билгеләнәчәкме? Моңа кадәр алган түләүләр гаиләнең кереме булып саналачакмы?

– Гаиләдә берничә бала булып, алар 0дән алып 17 яшькә кадәр каралган түләү шартларына туры килә икән, гаризада балаларның барысын да күрсәтергә кирәк. Бу очракта пособие барлык балаларга да бер үк күләмдә билгеләнәчәк. Ә моңа кадәр балаларга түләнгән акча исәпкә алынмаячак.

:: Бердәм пособиегә гаризаны Пенсия фонды аша гына җибәреп буламы? Әллә Дәүләт хезмәтләре порталы аша да ярыймы?

– Алдан әйткәнемчә, пособие яңа оешма – Социаль фонд тарафыннан билгеләнәчәк. Россия Пенсия фонды һәм Социаль иминият фонды берләшүдән гади халыкка берни дә үзгәрмәячәк диярлек. Киресенчә, моның уңайлы яклары күбрәк булачак. Мәсәлән, бала туганнан алып аңа 17 яшь тулганчы барлык төр социаль ярдәм чараларын бер урында күрсәтәчәкләр. Пособие билгеләүгә бәйле кагыйдәләр дә бер үк булачак. Хәзер исә алар баланың яшенә карап аерыла. Ә пособие һәр айның өчесендә күчереләчәк. Димәк, киләчәктә бер түләү килде, ә икенчесе юк дип баш катырып утырасы булмаячак.

Бердәм пособие нинди түләүләрне берләштерә:

- ➤иртә срокта исәпкә баскан йөкле хатын-кызларга айлык түләү;
- ➤беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә аңа 3 яшь тулганчы айлык түләү;
- ➤3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр (7 яшьлекләрне дә кертеп) балага айлык түләү;
- ➤8 яшьтән алып 17 яшькә кадәр (17 яшьлекләрне дә кертеп) балага айлык түләү.

ГОРУРЛАНЫРГА БЕР СӘБӘП

Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Әлеге юнәлештә эш алга таба дәвам итәчәк. Билгеле булганча, Татарстанда киләсе ел Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. «Киләсе елга тел, халыклар иҗаты, гореф-гадәтләребезне саклауга аеруча зур игътибар бирергә кирәк. Татарстанда яшәүче кайсы гына милләт вәкиле булмасын, без милли үзенчәлекләребезне, милләтара һәм динара дуслыкны югалтмаска тиеш», – диде Президент.

Милләт, дин турында сөйләшкәндә яшьләргә дә аерым игътибар иттеләр. Ни генә дисәң дә, бүген җыйган мирасны киләчәккә тапшыру эше аларга йөкләнәчәк. Әлеге уңайдан урта һәм һөнәри уку йортлары, вузларга да игътибарлырак булырга киңәш иттеләр. «Телен, милләтен, гореф-гадәтләрен хөрмәт иткән буын тәрбияләү бурычы көндәлек хезмәт кенә түгел, бу эш гаиләдән үк башланырга тиеш», – диде Рөстәм Миңнеханов. Бераз уйланып торганнан соң, яңадан шул сүзгә кайтып: «Без эшләмәсәк, моны тагын кем эшләр? Безнең өчен беркем дә тырышмаячак», – дип тә өстәде. Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләймановка мөрәҗәгать итеп, бу эшне балалар бакчасыннан ук башларга да тәкъдим итте.

Хәер, борчылырга җирлек юк. Һәрхәлдә, саннарга караганда. Ләйлә Фазлыева киңәшмәдә катнашучыларга республикада яшәүче яшьләр арасында үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләрен тәкъдим итте. Алардан «Татарстанда сез барыннан да бигрәк нәрсә белән горурланасыз?» дип сораганнар. Сораштыруда катнашучыларның 49 проценты республикада яшәүче милләтләрнең дустанә мөнәсәбәтен һәм үзара теләктәшлеген атаган. Беренче өчлеккә безнең якның табигате (54 процент) белән шәһәр архитектурасы һәм төзекләндерү (49 процент) дә эләккән.

«Бу – бик җитди сөйләшү, – диде Президент. – Милли традицияләр һәм гореф-гадәтләрне саклау, милләтара һәм динара дуслык бик мөһим. Бүгенге заманда күп кенә кыйммәтләрне югалту куркынычы бар. Шуңа күрә бергәләп тагын да тырышыбрак эшләргә туры киләчәк».

Эльвира ВӘЛИЕВА

Өлкәннәр тормышы

ЧӘЧЛӘРГӘ ЧАЛ КЕРСӘ ДӘ...

Ел бетмәгән, ә инде киләсе һәм алдагылары өчен максат, бурычлар бар. Татарстан өлкәннәре Бөек Җиңүнең 80 еллыгына бүгеннән үк әзерләнә башлады. Узып баручы елга ясалган нәтиҗәләр дә сөенерлек.

Өлкәннәр республика тормышында шактый эз калдыра. Мин ялда инде дип кул кушырып утырмый алар, җырлыйлар да, бииләр дә, иҗтимагый эшләрдә дә актив катнашалар. Татарстанның ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков, эшләгән эшләреннән канәгать икәнен яшерми. Залдагы өлкәннәргә ул: «Сез үз эшләрегез белән горурлана аласыз», – диде.

– Ел буе нәтиҗәле эшләдек. Дәүләт җитәкчеләре, төрле оешмалар белән бергәләп бик күп проблемаларны хәл иттек, – диде ул. – Ветераннар советы тарафыннан уздырылган чаралар да күп булды. Өлкәннәр яшьләр белән бик актив эшләде. «Иң яхшы беренчел оешма» бәйгесе быел Җиңүнең 77 һәм республика ветераннар советының 35 еллыгына багышланган иде. Анда катнашучы яңадан-яңа оешмаларның артуы сөендерә. Һәр районда, һәр авылда оешмалар булу безнең өчен бик кадерле.

Хәбир Иштирәков шушы бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләп тә китте. Очрашуда катнашкан Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Адель Мөбарәкшин өлкәннәр өчен оештырылучы тагын бер бәйге турында игълан итте. Баксаң, тиздән Баулы районының элеккеге рәисе Татьяна Кәлимуллина исемендәге бәйге узачак. Ул өлкәннәргә хезмәт күрсәтә торган социаль хезмәткәрләр арасында оештырыла. Бәйгедә җиңүчеләргә вакытсыз арабыздан киткән Татьяна ханымның эшмәкәр улы Леонид Кәлимуллин 30 мең сум күләмендә акча тапшырачак.

Өлкәннәрнең тик тормаганын беләсез инде. Ветераннар оешмасы күптән инде «Туган як» дип аталган акция башлап җибәргән иде. Бу чара кысасында өлкәннәр үз якташлары яшәгән интернат, картлар йортына барып, аларның хәлләрен белеп, күчтәнәчләр илтеп кайта. Әлеге матур гадәт тагын да дәвам итәчәк.

Республика ветераннар советының сугыш ветераннары белән эшләү һәм аларның исемнәрен мәңгеләштерү комиссиясе рәисе Татьяна Сабирҗанова өлкәннәрнең төрле бәйгеләрдә катнашып, грантлар отуларын да сөйләде. 2022 елда республиканың 10 ветеран оешмасы 3,6 миллион сумлык грант откан. Араларында берничә бәйгедә җиңүче районнар да бар икән. Үрнәк итеп Буаның ветераннар советын китерделәр. Алар хәтта Россия Президенты грантына кадәр откалар. Шул акчага бер авылда Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл дә куйганнар.

Плансыз эш булмый. Хәбир Иштирәковта инде 2023 елданиләр башкарасыларын тәгаенләп куйган. Алар Югары Ослан районына барып зур чара үткәрәчәкләр. Алабугада күчмә утырыш булачак. Яңа проектта да катнашачаклар. Ул «Җиңүнең 80 еллыгына 80 хатирә» дип аталачак. Аның кысасында җирле оешма ветераннары сугышта катнашучылар турында видеолар төшерәчәк. «Балкыш» фестиваленә дә әзерлек башланган инде. Татарстан өлкәннәре Волгоградтагы ветеран оешмасыннан үтенеч хаты да алганнар. Алар Волгоград шәһәренә элеккеге Сталинград исемен кайтарырга телиләр икән. Татарстан халкыннан тавыш бирүләрен сорыйлар. Безнекеләр исә каршы түгел.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Яшьләр һәм тугрылык:

ИКЕСЕН НИЧЕК БЕРЛӘШТЕРЕРГӘ?

Бүгенге яшьләр өчен ватанпәрвәрлек кайдан башлана? «Волга» эксперт клубының чираттагы утырышында әнә шул сорауга җавап эзләделәр. Очрашуда шулай ук дәүләт һәм яшьләр сәясәте турында сөйләштеләр.

Фикер алышуда катнашкан Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева сүзләренә караганда, яшьләр сәясәте түрәләрнең хисап кәгазьләрендә генә яшеренеп калмыйча, турыдан-туры яшь буынга кагылырга тиеш. Бу юнәлештә шактый эш алып барыла.

– Вазгыятьне аңлау өчен Татарстанда да, ил күләмендә дә социаль тикшеренүләр үткәрелә. Аның нәтиҗәләре дәүләт яшьләр сәясәте юнәлешендә нәрсәләр эшләргә тиеш икәнен ачыкларга ярдәм итә. Яшьләр өчен ватанпәрвәрлек ул – үз иленә, яшәгән төбәгенә, гаиләнә файдалы булу теләге, – диде Ләйлә Фазлыева.

Яшьләр сәясәтенең өлкән буынны да читләтеп узмавын әйтте вице-премьер. Шуңа күрә әлеге мәсьәләдә һәркемнең фикерен ишетү мөһим. «Мондый очрашулар бик кирәк. Чөнки җәмгыятьчелектә төрле сораулар туа һәм алар үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап табарга тырыша. Эксперт клубы утырышы кысасында күтәрелгән сорауларның барысы да «көн кадагы»нда тора», – диде танылган илкүләм сәясәтче Александр Асафов.

Чарада яшьләр сәясәтенә бәйле төрле фикерләр яңгырады. Утырышта армиядә хезмәт итүнең әһәмияте, махсус хәрби операциягә бәйле рәвештә яшьләрне берләштерү, яңа оешкан Бөтенроссия балалар һәм яшьләр илкүләм хәрәкәте турында да сөйләштеләр.

Андрей Большаков, Казан (Идел буе) федераль университеты Социаль-философия фәннәре һәм гаммәви коммуникацияләр институтының конфликтология кафедрасы җитәкчесе:

– 2022 елда илдә чыннан да җәмгыятьчелекнең берләшүе күзәтелә. Быелның декабрендә Россия Президенты Владимир Путин сәясәтен хуплаучылар күрсәткече 77–78 процентка җиткән. Бу бигрәк тә «өлешчә мобилизация» тәмамланганнан соң сизелә башлады. Халык мобилизациягә китүчеләргә, аларның гаиләләренә ярдәм итү, волонтерлык отрядлары оештыру кебек илкүләм бурычлар тирәсендә берләште. Татарстан да искәрмә түгел. Бу уңайдан кызыклы бер мисал: махсус хәрби операция игълан ителгәннән бирле республикада татар эстрадасы вәкилләренең берсе дә чит илгә чыгып китмәде. Халыкны берләштерүнең төп асылы гаилә, тел, мәдәният кебек кыйммәтләргә бәйле.

Зилә Вәлиева, Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе:

– Узып баручы елда иҗтимагый хезмәттәшлек, гуманитар ярдәмнең роле артты. Татарстанда волонтерлык хәрәкәтләре, коммерцияле булмаган оешмалар таяныч булырлык көчкә әйләнде. Бүген республикада 5 меңнән артык иҗтимагый һәм коммерцияле булмаган оешма бар. Алар күпсанлы социаль һәм гуманитар акцияләр оештыра. Һәркайсының эше аерым шәхесләргә бәйле. Мәсәлән, Украинада йортсыз, ашсыз калганнарга ярдәм кулы сузган Чаллы пешекчесе Рөстәм Гатинны гына алыйк. Бу ел әнә шундый кешеләрнең үрнәге белән истә калачак.

Яңа ел кәефе

Илдар Мөхәммәтҗанов

Өмет баглап көтәбез

Салмак кына адымнар белән Яңа ел якынлаша. Аның якынайганын тагын да сиздереп, базарларда, зур сәүдә үзәкләре каршында төп бәйрәм бизәге – чыршы саталар. Ә сездә бәйрәм кәефе бармы? Йортларыгызда чыршылар бизәдегезме әле?

Гөлнур ФӘТХЕТДИНОВА (Чистай районы Исләй авылы):
– Мин клубта эшлим. Быел халыкта да, артистларда да, үземдә дә бәйрәм кәефе юк. Артистларым да сүлпән. Балам кечкенә булгангамы, үзем дә йөгерә-йөгерә алдан йөрмим. Ә менә өебездә өч бала булгач, Яңа ел кәефе тудырырга тырышабыз. Әтиләре кичә Чистайдан чыршы алып кайткан. Бүген шуны балалар белән бизәдек, кәефләре күтәрелеп китте, бик сөенделәр инде. Узган ел ясалма чыршы гына куйган идек. «Тере»гә җитми инде. Исе өйгә чыга, бәйрәм атмосферасы тудыра. Аннан соң аны мунчага алып барып, суда тонәтеп юынабыз.

Венера АИТОВА (Казан):
– Мин Яңа ел бәйрәмен һәрвакыт ярата идем, ә балалар туугга аңа караш тагын да үзгәрде. Могҗиза көтү, балалардай сөенү, хисләрне оялмыйча күрсәтә алу мөмкинлеге дип кабул итәм аны. Шуңа күрә, әйе, Яңа ел кәефе бар. Ул һава торышы белән дә, өйне бизәү белән дә килде. Тик әлегә чыршы куймадык. Без әле дә уйда, чөнки Гаяз чыршыны аудармасмы, дибез. Без генә түгел, әниемнәр дә бәйрәмне көтеп ала. Ел саен ике метрлы чын чыршы бизиләр. Хуш исле, бөтенләй башка атмосфера тудыра бит ул өйдә. Гомумән, Яңа ел – якыннарны бүләкләр биреп сөендерер, кадерле кешеләрне кадерләр өчен шәп мөмкинлек. Бөтен кешенең күңеле өмет белән тулыдыр бүген. Быел халык аеруча тылсым, могҗиза көтәдер шикелле. Моны башкалар да шулай ди. Чәчтарашым да шуны искәртте. Бер килмәгән кешеләр дә быел алдан язылып куйды, Яңа елга әзерләнә, ди. Кызганыч, Яңа ел тамашалары күп булса да, гриппның котырган чагы. Балалар белән барырга шикләндерә.

Гөлназ ИСЛАМОВА (Азнакай районы Мәнәвез авылы):
– Яңа ел кәефе юк, дип әйтеп булмый. Авылдашлар белән бергәләп клуб янын бизәдек, кардан сыннар ясадык. Әлегә чыршы куймадык, ләкин ел да «тере»не бизибез. Аның исе дә, матурлыгы да башка инде. Декабрь ахырында матур итеп Чыршы бәйрәме уздырырга ниятлибез. Гомумән, быелның соңгы аенда клубыбызда чаралар күп узды. Өйдә дә бәйрәм рухы булдырырга тырыштык.

Ләйсән ГАЙСИНА (Актаныш):
– Ирем белән ике бала тәрбиялибез. Әтиләрен октябрьдә хәрби операциягә мобилизацияләделәр. Минем үземдә бер дә бәйрәм кәефе юк. Тик балалар барыбер бәйрәм көтә. Чыршы бизәргә дә, өйгә матур итеп гирляндалар эләргә дә алар тәкъдим итте. Ел саен ясалма чыршы куябыз, чөнки мәшәкате азрак, бәясе дә арзангарак төшә. Шулай да, ис чыгарыр өчен, чыршы ботаклары алып куярмын дип уйлыйм. Анысы белән проблема юк, адым саен «тере» чыршы саталар. Быел да балалар чыршыны икесе бизәде. Улыбызга – 10 яшь. Ул инде барысын да аңлый, әтисен дә ныграк сагына, юксына. Мөмкинлек булган саен аның белән телефоннан шалтыратып сөйләшә. Үземә дә авыр, тик ничек кенә булса да, сиздермәскә тырышам. Әле менә балаларның икесен дә Казанга Президент чыршысына алып барачаклар. Анысына бик сөендек инде. Балалар ул көнне түземсезлек белән көтә.

Рәмзилә ХӘМӘТОВА (Чаллы):
– Яңа ел кәефе бар инде ул. Булмаса да, булдырырга тырышабыз. Чөнки Яңа ел матур хәбәрләр алып килер, дип бик нык өметләнәбез. Ниһаять, илебезгә тынычлык килсен иде. Өйне дә бизәдек, чыршыны да куйдык. Анысын ясалманы сайлыйбыз, чөнки «тере»се матур булса да, бәйрәмнән соң мәшәкате күп.

Гөлфинә ГЫЙБАДУЛЛИНА (Биектау):
– Яңа ел кәефе бар да, юк та төсле. Берничә атна элек кенә зур сөенечебез булды – беренче тапкыр әни булдым. Хуш исенә исереп, бәби карау мәшәкатьләренә чумган көннәребез. Шул ук вакытта күңелдә тынычлык юк – бертуган абыем мобилизациянең беренче атналарыннан ук яу кырында. Башта бик авыр булды, хәзер бераз гына тынычрак шикелле. Барыбыз да – әни дә, хатыны белән ике баласы да аның өчен ут йотып торабыз. Шуңа күрә без Яңа елдан бары тик яхшы хәбәрләр генә көтәбез.

Марат АКСАНОВ (Казан):
– Ике кызыбызның күңелен күрер өчен, чыршыны декабрь башында ук бизәп куйдык. Өлкәннәрнең кәефенә, дөньядагы хәлләргә карамастан, балалар могҗиза көтә бит. Чыршының ясалмасын сайлыйбыз, үзебез кечкенә вакытта да әти белән әни гел шундыйны куя иде. Олыларның кәефен шәп дип әйтеп булмый. Чөнки киләсе елга билгесезлек белән керәбез. Арыслан усаллыгын күрсәтте, инде Куянның йомшаклыгын көтәбез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

300 ЕЛДАН СОҢ ЯРДӘМ

Тарих эзләреннән

Башкалабыздагы Бишбалта бистәсенең Россиядәге корабльләр төзелешенә нигез салучы балта осталарын мәңгеләштергән хезмәт ветераны Гарәфетдин Хисаметдинов сөенече белән уртаклашты. Ул шушы проекты белән Россия милли культуралары бәйге-фестивалендә I дәрәҗә дипломга лаек булган.

Һәйкәл

«Бишбалта остазлары» дип аталган бу һәйкәлне элек «Урак һәм Чүкеч» заводы карамагында булган Николай Столяров скверына ветеран үз акчасына ясата. Һәйкәлнең тарихы Петр Iгә бәйле. Белгәнебезчә, Петр I, Казан янында урнашкан Бишбалта авылында кораблар төзүчеләр яшәгәнен белеп, Адмираллык төзү турындагы указны 1718 елда имзалый. Һәм 25 кораб төзергә боерык бирә. Шуннан соң биредә урман кисүче, агач эшкәртүче лашманчылар барлыкка килә. Аннары акрынлап күн эшкәртү артельләре, җилкәннәр, брезентлар әзерләү өчен җитен комбинаты, судноларны корал белән тәэмин итү өчен дары заводы эшләп китә. Суднолар ремонтлау һәм металл әйберләр – якорь, чылбыр ише кирәк-яракны җитештерү эшләре башлана. Бөек император 1722 елда бер көнгә генә Казанга килә, 50 яшьлек юбилеен бәйрәм итә. Шунда Бишбалта авылы балта осталарының эшен күреп хәйран кала. Алар төзегән корабларга утырып, Хазар диңгезенә Иранны яуларга китә. Көньякта урнашкан диңгезләргә чыгу хыялын тормышка ашыру йөзеннән, Россия флотын яңарту уе әнә шул чакта Петр Iдә кабат раслана.

Гарәфетдин абый шундый зур эш эшләсә дә, барыбер төшенкелеккә бирелеп йөри иде әле. Һәйкәл салырга хакимияттән рөхсәт тә ала ул, эшен кабул да итәләр. Әмма ачылу тантанасы гел сузыла килә. Моңа пандемия дә тәэсир итә булса кирәк, чөнки Петр Iнең Казанга килүенә 300 ел булуга багышланган бәйрәм дә шул сәбәпле кичерелә бит. Һәм... уйламаганда-көтмәгәндә мәсьәлә хәл ителә.

Бәйрәмне зурлап үткәрү максатыннан, Мәскәүдән һәм Санкт-Петербургтан кунаклар килә.

– Күрәсең, һәйкәл шул җәһәттән исләренә төшкәндер. Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова әмере буенча, аны ачу тантанасына әзерләнүләре турында хәбәр иттеләр. Димәк, Петр I минем кебек татарларга 300 елдан соң да ярдәм иткән булып чыга, – ди Гарәфетдин абый, уенын-чынын бергә кушып.

Шул чарада аңа бәйгедә катнашырга тәкъдим итәләр дә инде.

– Сынчы Зөлфия Мөхәммәтҗанованың фикерен белеп, ризалыгын алып, катнашырга булдым. Җиңеп чыкканымны белгәч, башта ышанмыйчарак тордым. Белешмәне үз кулларым белән күргәч кенә дөрес икәнлегенә төшендем, – ди ул бу җәһәттән.

Туристлар өзелеп тормас

Гомере буена диярлек Бишбалтада эшләгән һәм яшәгән, бүген аның тарихын барлаучы Гарәфетдин абыйның хыялы – бу бистәгә туристларны җәлеп итү.

– Хәзер Казанга туристлар күп килә, – дип фикер йөртә ул. – Аларга, әлбәттә инде, беренче чиратта Кремль территориясен, Иске Татар, Яңа Татар бистәләрен күрсәтәләр. Киров районына да чыгалар, чөнки анда Илдар Ханов төзегән Барлык диннәр храмы бар. Абыйсының эшен хәзер энекәше Илгиз дәвам итә. Шунда барганда, хәтта игътибар да ителмичә, юл өстендә Бишбалта кала. Югыйсә бу Казанда тарихка бай иң борынгы татар авылы бит. Хәтта исеме дә бүгенгә кадәр сакланган. Ни кызганыч, күпләр бу хакта белми дә. Әле адмираллык төзелгәнче үк, 1710 елда Бишбалтадан биш корабтан торган эскадра – Балтыйк диңгезенә, сигез корабтан торганы Азов диңгезенә юл тота. Шуларның берсе «Казан шәһәре» дип атала. Петр I указы чыкканнан соң, 25 кораб Идел буйлап Хазар – Каспий диңгезенә юл ала. Император үзе дә шунда була. Адмираллык булган чорда Бишбалтада 400 кораб төзелә.

Әйтергә кирәк, Гарәфетдин абыйның хыялы өлешчә тормышка ашкан инде. Татарстан Милли музееның экскурсия бюросында Бишбалтага ике сәгатьлек сәяхәт теркәлгән. Әмма ветеран һәр күренешне камилләштерү өстендә эшләргә кирәк дип саный.

– Максатым – Бишбалтада татар тормышын саклап калу, – ди ул. – Монда яшәүче халык кулына балта тотып эшләү белән генә дан казанмаган. Алар Казан ханлыгын торгызу эшендә дә бик актив булганнар. Авыл кешеләре Кремльнең агач диварларын, эчке корылмаларын эшләгәннәр. 1552 елда Зөя утравыннан су юлы белән килгән Явыз Иван гаскәрләренә каршы беренчеләрдән булып көрәшкә күтәрелгәннәр. Соңрак шулай ук беренчеләрдән булып Петр I, Екатерина IIне каршылаганнар. Бишбалта осталары Россиянең башка адмиралтыкларында, мәсәлән, Воронежда, Санкт-Петербургта, Әстерханда эшләгәннәр. 1829 елда Бишбалта адмиралтыгын Әстерханга күчерәләр. Революциядән соң Бишбалта эшчеләре совет властен торгызуда, ә 1918 елда шәһәрне ак чехлардан һәм ак гвардиячеләрдән саклауда да зур роль уйныйлар.

– Бүген Идел буендагы борынгы татар зиратын да мирас исемлегенә кертергә кирәк дип саныйм. Ни кызганыч, аның бер өлеше су астында калган инде, шул территориядән ком чыгарырга ниятлиләр. Бишбалтаның тирә-юненнән дә татар рухы бөркелеп тора. Мәсәлән, Аракчиноны гына алыйк. Ул «уракчы» дигән татар сүзеннән алынган. Монда элек уракчылар яшәгән һәм патша армиясе өчен печән әзерләгән.

Меценат

Татар халкы, бигрәк тә Бишбалтада яшәүчеләр Гарәфетдин Хисаметдиновны меценат буларак бәяли. Ул үзе Кукмарада туып үскән. Татар мәктәбендә 8 сыйныфны тәмамлагач, Ижау шәһәренә һөнәри училищега укырга киткән. Белем алырга теләк аны Казанга алып кайта. «Урак һәм Чүкеч» заводына слесарь булып эшкә урнаша. Укып тормыйча гына имтиханнар биреп, урта белем турында аттестат ала һәм КАИга укырга керә. Заводта – мастер, аннан инструменталь цехның начальнигы була. Нәкъ менә шушы цехта сугыш вакытында физик, атом-төш белгече Игорь Курчатовның «Уран» лабораториясе урнаша. Монда галим илебездәге атом-төш коралы фәненә нигез сала. Шунысы гаҗәп: предприятие үзе инде күптән юк, ә әлеге цех һаман исән. Аны хуҗасы арендага бирә. Гарәфетдин ага менә шул цехның фасадына Курчатов турында истәлек тактасы куярга йөри. Бина хуҗасының рөхсәте бар, хакимият һәм күзәтү органнарыннан гына ризалык алырга кирәк. Монысы, гадәттәгечә, озаккарак сузылыр дип уйлый ул.

Заводта Хисаметдинов партком секретаре була, югары партия мәктәбендә белем ала. Узган гасырның туксанынчы еллар башында тагын бер югары белем ала – Казан финанс-икътисад университетын тәмамлый һәм «Заречье» банкы идарәсе рәисенең урынбасары булып эшли. Соңрак, үз фирмасын төзеп, Николай Столяров урамында күпкатлы йортлар төзи.

Вакыт үтеп, зур эшләрдән арынгач, ул Бишбалта тарихын өйрәнү белән мавыгып китә. Хәзер шул хакта китап язу белән мәшгуль. Бистәдә урнашкан 15 нче татар гимназиясе белән дустанә мөнәсәбәттә яши. Бу уку йортының да бинасы бик истәлекле. Анда инкыйлабка кадәр хатын-кызлар гимназиясе урнашкан була.

...Башкалабызның Үзәк паркында «канатлы» юлларны хәтерләүчеләр бардыр әле. Аны кайчандыр Бишбалтадагы «Урак һәм Чүкеч» заводында эшләгәннәр. Революциягә кадәр үк төзелеп, халыкны агарту эшләренә зур өлеш керткән «Йолдыз» кинотеатрын да онытып бетермәгәннәрдер. Бишбалтаның Идел ярындагы күңел ачу урыннары да әдәби әсәрләрдә урын алган. Димәк, анда тормыш гөрләп торган. Гарәфетдин Хисаметдинов әнә шул матурлыкны кайтару һәм Бишбалта мохитен саклау уе белән яши.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТОРМЫШ ДӘРЕСЕ

Соклану

Гаиләм янында мин бәхетле. Саба районының Югары Шытсу авылында яшәүче Гөлнар Шәрифуллина әнә шулай ди. Тынычлык, сабырлык булган гаиләдә генә эшләр уңа, күңелгә рәхәт, биисең дә, җырлыйсың да килә. Әлеге гаиләне бөтен Татарстан белә хәзер. Гөлнар ханым республика күләмендә узган «Нечкәбил» бәйгесендә гран-при отып, «Иң Нечкәбил» исеменә лаек булды. Алар әле дә җиңүләренә ышанып бетә алмый.

– «Нечкәбил»дә катнашырга дигәч, башта югалып калдык. Чөнки бу бәйгедә гаиләңне генә түгел, бөтен район данын да яклыйсың бит! Без «Нечкәбил»нең бик зур сабырлык, көч таләп итә торган бәйге икәнен ишетеп белә идек. Алдан үзебезне шуңа әзерләсәк тә, барыбер борчылдык, – ди Гөлнар ханым. – Башымда май аеннан бирле мең төрле уй кайнады. Соңрак артка юл юк, барсак, бары алга гына, дип, барлык биремнәрне булдыра алганча үтәп, финалга килеп җиткәнне сизми дә калдык. Бәйгедә гаилә кыйммәтләренә зур урын бирелсә дә, үзең генә ерып чыга торган чара түгел иде. Дуслар, туганнар, җитәкчеләр, хезмәттәшләр ярдәме бик кирәк булды.

26 ел буе мәктәптә балаларга белем биргән Гөлнар ханым 4 ел элек ире Илшат янына мәдәният йортына эшкә күчкән. Илшат бу өлкәдә 32 ел хезмәт куя икән инде. Башта Илшатның әти-әнисе дә клубта эшлиләр.

– Ирем белән 1996 елның 8 мартында гаилә корып җибәрдек. Шул ук елның декабре безгә икеләтә шатлык алып килде: 25е өебезгә газ керде, ә 29ында олы улыбыз Фәнзил туды. Тагын ике елдан кызыбыз Зәринә дөньяга аваз салды. «Бу нигезгә беренче кыз алып кайттың», – дип әткәй-әнкәй бик сөенделәр инде. Олы улыбызга да, кызыбызга да шигырьләр язды каенатам. Әкиятләр сөйләргә дә оста иде, мәрхүм. Әткәй безнең балаларны да әкият белән үстерде. Кызганыч, кечкенә улыбызга гына аның әкиятләрен тыңлау насыйп булмады. Кечкенәбез

Рәзилне 2005 елда алып кайттык, – ди Гөлнар ханым. – Әткәебез гомер буе гаиләбез турында көндәлек алып барды. Хәзер аны без дәвам иттерәбез. Анда балаларыбызның кечкенә чагы турындагы истәлекләр бик күп.

Кайвакыт Шәрифуллиннардан: «Гел бергә булу арытмыймы?» – дип тә сорыйлар икән. Әмма алар инде бу сорауга төгәл җавап бирә: икең бер булып яшәгән кешегә тәүлек буе бергә булу да җитми әле!

– Гел бергә булу барлык авырлыкларны да җиңеп чыгарга, тормыш ваклыкларын дөрес итеп кабул итәргә ярдәм итә, – ди Гөлнар ханым. – Балаларыбыз да безнең юлдан бара. Олы улыбыз төрле уен коралларында уйный, барбер хезмәте дә күрсәтә. Кызыбыз бухгалтер, кечкенәдән җырлап, курайда уйнап үсте. Кечкенә улыбыз Арча педагогия көллиятендә музыка бүлегендә укый. Ирем курайлар, окариналар ясый. Бу шөгыль шулай ук бабайдан һәм әткәйдән күчкән. Хәзерге вакытта без бу эшне гаиләбез белән дәвам иттерәбез, күргәзмәләр оештырабыз, мастер-класслар күрсәтәбез.

Алар гаилә кыйммәтләрен, гореф-гадәтләрен саклап яши. Бабаларыннан калган тальян гармунны да, каенанасының әнисеннән калган сөлге, чулпы, Гөлнарның әбисеннән калган гәрәбә муенса да зур истәлек булып тора. Шул истәлекләр арасында иң кадерлесе – Коръән китабы. 1959 елда каенатасының өе янып бетә. Бары тик әбиләренең Коръәне генә янмый кала.

Шәрифуллиннарның бар максатлары да – үзләренең тормыш букчасында булган кадерле ядкарьләрне түкми-чәчми балаларга, оныкларга тапшыру. Шөкер, инде улы Фәнзил Лилия исемле кызга өйләнеп, гаиләле булды, хәзер әби-бабай оныклары Тимерланны сөя. Кызлары Зәринә дә Айдар исемле егет белән күптән түгел гаилә корып җибәргән.

Матур итеп төзегән гаиләңне ничек сакларга? Гөлнар Шәрифуллинадан бәхетле яшәү серләрен белештек. Баксаң, бар да гади икән. Әти-әни биргән киңәшләрне тотсак, гаиләңне сакларга була.

– Тормыш юлларын узганда бер-береңне аңларга, кайчагында юл куя белергә, кайдадыр күрмәмешкә салышырга, ишетмәскә дә кирәк. Балаларны исә сөеп-яратып үстерү янына хезмәт тәрбиясен дә кушыгыз. Гаиләдә ешрак бергә җыелышу аны тагын да ныклы итә, – ди Гөлнар ханым. – Хатын-кыз буларак мин бик бәхетлемен. Гаиләмнең мәхәббәтен, хөрмәтен тоеп яшим. «Нечкәбил» бәйгесенә килгәндә, мин аны бик яратып кайттым. Әзерләнгәндә күңел төшкән чаклар булса да, шөкер, җиңеп кайтуыбыз барысын да онытырды. Анда катнашкан һәр гаилә хөрмәткә лаек. Мондый бәйгеләр бик кирәк. Ул күпме гаиләне берләштерә, яңа дуслар, гореф-гадәтләр белән танышасың, үз-үзеңә ышаныч арта, ниндидер омтылыш барлыкка килә һәм, иң мөһиме, үзеңнең нәселеңнең, гаиләңнең күпме истәлекләре барлана, ядкарьләре ачыклана, архив барлыкка килә. Бу безгә бер тормыш дәресе булды дисәк тә, ялгыш булмас.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 389

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты
(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+